КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 15 декабрь г.Казань № 995

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Бюджет өлкәсенең Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында" 2006 ел, 15 июнь, 304 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Бюджет өлкәсенең Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында" 2006 ел, 15 июнь, 304 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 206 ел, 2 октябрь, 488 нче; 2008 ел, 4 февраль, 66 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «1 - 4 нче кушымталар нигезендә» сүзләрен «1 - 5 нче кушымталар нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

5 нче кушымта өстәргә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2006 ел, 15 июнь, 304 нче
карарына 5 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 15 декабрь, 995 нче
карары редакциясендә)

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы аппараты»
дәүләт казна учреждениесе хезмәткәрләренең
вазыйфаи окладлары күләме

| Вазыйфа исеме | Вазыйфаи оклад күләме, сум |
|---|---|
| Җитәкче | 10660 |
| Җитәкче урынбасары | 6365 |
| Баш референт | 6365 |
| Әйдәп баручы белгеч | 5852 |
| Әйдәп баручы белгеч (бухгалтер) | 5852 |
| Референт | 5297 |